# Газиз Кашаф - Үзиле



Журналыбызның беренче саны белән укучыларыбызны никадәр сөендерергә, шатландырырга теләсәк тә, булып ук җитмәде, яңа көн безгә кайгылы хәбәр алып килде. Ни хәл итәсең бит, язмыш һәр гамәлебезгә үз төзәтмәсен кертә.

Рәхимсез үлем арабыздан талантлы каләмдәшебез, игелекле якын дустыбыз, язучы Газиз Кашаф Үзиле (Газизҗан Салихҗан улы Кашаповны) алып китте. "Аргамак" исемен журналга ул тапкан иде.

Гомеребез, яшәешебезнең һәр мизгеле катлаулы заманга, киеренке чорга туры килде. Әмма кайбер очракта авырлыкның ил өстенә килгәне дә, үз өстеңә килгәне дә артык күбәеп китә һәм йөрәк белән җанны тоташтыручы җеп түзә алмый, шартлап өзелә. Каләмдәшебез, талантлы прозаик Газиз Кашаф Үзиле белән әнә шулай булды.

Озакка сузылган каты авырудан соң, 30 август көнне иртән татар язучысы Газиз Кашаф Үзиле вафат булды.

Газиз Кашапов 1942 елның 21 августында Татарстанның Аксубай районы, Яңа Үзи авылында туа. Кечкенәдән әти-әнисез калып, әбисендә үсә. Башта туган авылында җидееллык, аннары Иске Ибрай авылы урта мәктәбен тәмамлый. Колхозда бухгалтер ярдәмчесе, тракторчы һәм клуб мөдире булып эшли. Аннары Совет Армиясендә хезмәт итә. Хәрби училище тәмамлый, офицер була. 1968 елда Чехословакиядәге булган чуалышлар вакытында авариягә очрап, аңа хәрби хезмәт белән саубуллашырга туры килә.

Г.С. Кашапов читтән торып Казан дәүләт университетының татар теле һәм әдәбияты бүлеген тәмамлый. 1974-78 елларда Татарстан китап нәшриятында кадрлар бүлеге инспекторы, Әлмәт районында чыга торган "Хезмәт байрагы" газетасында әдәби хезмәткәр булып эшли. 1978 елда Чаллы шәһәренә күчеп килә. Биредә КамАЗ радиотапшырулар редакциясендә хәбәрче, аннары "Социалистик Татарстан" газетасының Түбән Кама, Алабуга, Мамадыш районнарындагы үз хәбәрчесе һәм Чаллы язучылар оешмасында пропаганда бүлегендә эшли.

1983 елда СССР Язучылар союзына кабул ителә. 1988-1989 елларда Чаллы язучылар оешмасының җаваплы секретаре итеп сайлана.

Газиз Кашаф Үзиле әдәбиятка укучы тарафыннан яратып каршыланган "Сәмум җиле" исемле повесте белән килеп керде. Аннары Татарстан китап нәшриятында аның бер-бер артлы "Еллар тыныч иде", "Язмышыңа ышан", "Гомернең утлы өлеше", "Вөҗдан хәтере" дигән китаплары дөнья күрде. Соңгы елларда ул татар халкының сөекле шагыйре Хәсән Туфан турында роман язарга кереште. Аның беренче өлешен тәмамлады да. Соңгы көннәрдә генә "Тилчә тамыры" дигән әсәрен язып бетергән иде.

Газиз Кашапов каләмдәшләре күңелендә эшчәнлеге, тырышлыгы, самимилеге, милләткә бирелгәнлеге белән уелып калды. Вакытсыз үлем аны иҗатының чәчәк аткан чорында арабыздан йолкып алды. Әмма аның якты истәлеге, әсәрләре күңелләребездә мәңге сакланыр.

*Чаллы шәһәр Совет Президиумы һәм шәһәр Советы башкарма комитеты, КамАЗ акционерлык җәмгыяте, Чаллы язучылар оешмасы, "Аргамак" журналы мөхәрририяте.*